**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №148-24 «25» октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 12 октябрендәге 98-18 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында” карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында (14.12.2022 №105-19, 18.04.2023 №116-21 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 04 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 12 октябрендәге 98-18 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында” карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (14.12.2022 №105-19, 18.04.2023 №116-21 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 42 статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 43 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «программаны раслаган шәһәр Башкарма комитеты карары нигезендә» сүзләрен «шәһәрнең Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «билгеләнгән срокларда» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль программалар бюджет турындагы механизм агымдагы финанс елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча туры китерелергә тиеш.»;

3) 44 статьяның 2 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле өченче - бишенче абзацлар өстәргә:

«транспорт салымыннан җирле бюджетлар керемнәре (әгәр Россия Федерациясе субъекты законы белән җирле бюджетларга транспорт салымыннан чигерүләрнең бердәм нормативлары билгеләнгән булса);

җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау исәбенә җирле бюджетлар керемнәре;

авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасының хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозган өчен җирле бюджетлар керемнәре;»

өченче абзацны алтынчы абзац дип санарга;

49 статьяның 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 12 октябрендәге 98-18 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында” карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы нигезләмәнең 44 статьясындагы дүртенче һәм бишенче пунктлары нигезләмәләре (әлеге карар редакциясендә) Азнакай муниципаль районы бюджетын 2024 ел бюджетыннан башлап, 2025 һәм 2026 еллар план чорына төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин